СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
«15» ноябрь 2021 ел.

**КАРАР**
№ 34

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты һәм «Авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында» 8.10.20021 елдагы 84 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы Карары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге, Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Пыжмара авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 76 номерлы карары (2016 елның 12 декабрендәге 39 номерлы, 2018 елның 31 августындагы 82 номерлы редакциясендә) үз көчен югалткан дип тану турында»2019 елның 30 апрелендәге 106 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының 31.05.2013 ел, № 76 «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» гы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре» нә (2016 елның 12 декабрендәге 39нчы, 2018 елның 31 августындагы 82нче редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 35.1. статьяның Ж-1 өлешендә Шәхси торак йортлар төзү зонасы авыл җирлекләрендә гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең минималь күләмен билгеләргә:

шәхси торак төзелеше өчен – 0,10 га мәйданда;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен – 0,10 га кадәр мәйданда;
бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек өчен-0,15 га кадәр.

2.2. 35.1. статьяның таблицадагы Ж-1 зонасында «Аерым торучы индивидуаль торак йорт», «Блокланган торак йортта бер гаиләгә торак берәмлек» «600» санын «1000» санына алмаштырырга.

2.3. 35.2 статьяның «Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төрләрен» авыл җирлекләрендә гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең минималь күләмен билгеләргә:

шәхси торак төзелеше өчен – 0,10 га мәйданда;
шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен – 0,10 га кадәр мәйданда;
бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек өчен - 0,15 га кадәр.

2.4. 35.1. статьяга үзгәрешләр кертелде. Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналар. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре 11 бүлеге түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең минималь күләме-1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең максималь күләме -2 500 кв. м.»

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://pravo.tatarstan.ru/

4. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең төзекләндерү, төзелеш, хокукларын яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы: Р.Х.Заляев